**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**"04" сентябрь 2018 ел** **№ 71**

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Кама Тамагы районы Варварино авыл җирлеге Уставының 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Варварино авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Варварино авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсәлә буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыкты:

   "2019 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 300 сум үзара салым кертү белән килешәсезме, һәм җыелган акчаларны, киләсе эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

   * - җирлек торак пунктлары чикләрендә территорияләрне төзекләндерүне кагыйдәләр нигезендә оештыру;
   * - җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
   * - җирләү урыннарын тәртиптә тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру;
   *- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;
   * - коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортировкалау эшчәнлеген оештыру.

2. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерү:
1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Көрәле авылы, Үзәк ур., 2а;
2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Варварино авылы, Ленин урамы, 32;
шулай ук «Волжские зори» («Идел таннары») газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, «Идел таннары» район газетасының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Варварино авыл җирлеге Башлыгы Р.Т. Нотфуллинга йөкләргә.

“Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Варварино авыл җирлеге”
башлыгы, “Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Варварино авыл җирлеге”
Советы рәисе Р.Т.Нотфуллин